**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2017 Балык Бистәсе штп. № 95пи

Гадәттән тыш хәлләрдә җәмагать тәртибен саклау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында»гы 1994 елның 21декабрендәге, 68-ФЗномерлы Федераль законның 11 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында«карары 2003 елның 30 декабрендәге, 794 номерлы карары, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының "Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать куркынычсызлыгы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау турында" 2001 елның, 28 сентябрендәге, 858 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турында Нигезләмәне расларга

2. Гадәттән тыш хәлләр вакытында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруда катнашучы барлык службалар, оешмалар һәм учреждениеләрнең эш-гамәлләрен җитәкчелек итүне һәм координацияләүне һәм җәмәгать тәртибен саклауны оештыруны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы ,Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Д. Ә. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 15 маендагы 95 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турында Нигезләмә**

1.Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау тәртибен билгели.

2.Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе тарафыннан гадәттән тыш хәл килеп чыкканда һәм турыдан-туры гадәттән тыш хәл зонасында хокук тәртибен һәм оешканлыкны саклау максатыннан оештырыла.

3.Җәмәгать тәртибен саклауны турыдан-туры оештыручы булып Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) тора.

4.Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауның төп бурычларына түбәндәгеләр керә:

- халыкны эвакуацияләү һәм коткару эшләре вакытында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

-районда урнашкан аеруча мөһим объектларны саклау;

-- районда гадәттән тыш хәл режимын үтәүне, РСЧС көчләрен һәм чараларын урнаштыру районнарында һәм махсус техника эшкәртү пунктларында контрольдә тоту;

-хокукка каршы гамәлләр, ялган һәм провокацион имеш-мимешләр таралуны, мөмкин булган массакүләм тәртипсезлекләрне кисәтү;

- радиоактив зарарлану зоналарына, химик, биологик (бактериологик) зарарлану учакларына керү режимын үтәүне һәм аларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту;

- эвакуацияләнгән халыкны, аның югалтуларын һәм зыян күрүчеләрне исәпкә алуны оештыру;

- районда гадәттән тыш хәлне тәэмин итү бурычларын хәл итү өчен көч һәм чаралар әзерләү.

5. Районда җәмәгать тәртибен тәэмин итү бурычларын үтәү өчен гадәттән тыш хәл вакытында көч һәм чаралар җәлеп ителә:

-Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге ( килешү буенча);

-Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлекчәсе (килешү буенча);

-Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының өстәмә бүлекчәләре (килешү буенча) (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы карары буенча эре масштаблы гадәттән тыш хәлләрдә).